ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ

ШӘРБӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

2 нче номерлы

2020 елның 2 нче мартыннан

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл җирлеге башкарма комитетының
«2016-2020 елларга Шәрбән авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү” муниципаль
максатчан программасын раслау турында”
**2015 елның 13 нче ноябрендәге 11 номерлы**
карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль берәмлекнең хокукый базасын Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясы таләпләренә туры китерү, “Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 27 декабрендәге 104 - ФЗ номерлы Федераль закон редакциясендә, программа-максатчан планлаштыру тәртибен камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Уставына таянып,

КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге башкарма комитетының «2016-2020 елларга Шәрбән авыл җирлеге территориясен төзекләндерү" муниципаль максатчан программасын раслау турында" **2015 елның 13 ноябреннән 11 номерлы** карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "2016-2020 елларга Шәрбән авыл җирлеге территориясен төзекләндерү" муниципаль программасын раслау турында".
1.2. Программа тексты буенча "муниципаль максатчан программа" сүзләрен "муниципаль программа" сүзләренә алмаштырырга, тиешле килештә һәм санда.

2. Программага кушымта итеп бирелә торган редакция нигезендә кушымтаны бәян итеп, чаралар юнәлешләре буенча финанслау күләмнәрен бүлү өлешендә үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ә.Шәрифуллин

Программага кушымта.

«2021- 2025 елларга авыл җирлеге территориясен төзекләндерү» муниципаль программасының төп чаралары.
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының “Шәрбән авыл җирлеге”.

| № т/б | Чаралар | Еллар буенча чаралар үтәлеше | | | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | |
| 1 | Автомобиль юлларын һәм инженерлык корылмаларын карап тоту, торак пунктларның урамнарын кардан чистарту | 7 км 10000 сум. | 7 км 10000 сум. | 7 км 10000 сум. | 7 км 10000 сум. | 7 км 10000 сум. | Финанслау күләме. Программа прогнозланган характерда һәм тиешле елга тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук чараларны финанслашуга республика һәм район бюджетыннан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. |
| 2 | Торак пунктларның урамнарны яктырту | 7 км 146000 сум | 7 км 146000 сум | 7 км 146000 сум | 7 км 146000 сум | 7 км 146000 сум | |
| 3 | Күмү урыннарын оештыру һәм карап тоту | 1 зират 2000 сум | 1 зират 2000 сум | 1 зират 2000 сум | 1 зират 2000 сум | 1 зират 2000 сум | |
| 4 | Чишмәләрне төзекләндерү, данә | - | - | - | - | - | |
| 5 | Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү, данә | - | - | - | - | - | |
| 6 | Обелискларны төзекләндерү, данә | - | - | - | - | - | |
| | Барлыгы | | | | | | |